ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2006, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары федераль дәүләт фәнни оешмаларда, югары белем бирү федераль дәүләт мәгариф оешмаларында фәнни тикшеренүләр һәм (яисә) эксперименталь эшләнмәләр үткәрүне, федераль дәүләт фәнни оешмаларны үстерү программаларын яисә планнарын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итәргә, шулай ук әлеге фәнни оешмаларның инфраструктурасын булдыруда катнашырга хокуклы.».

**2 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), аңа «тәэмин итәргә» сүзләреннән соң «, шулай ук югары белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы федераль дәүләт оешмаларында югары белем алуны һәм бу оешмаларны үстерү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итәргә, шушы

оешмаларның уку-укыту, җитештерү, социаль инфраструктурасын булдыруда катнашырга» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 18 июнь
№ 31-ТРЗ